СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«18» июль 2017 ел** **№ 134**

**Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 331 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү , класслы чиннар бирү өчен квалификация имтиханнарын кабул итү, муниципаль хезмәттә эш стажын билгеләү һәм аның тиешле еллар эшләгән чорын исәпләү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 02.03.2007 №25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 331 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә, Муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 №50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 331 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү, класслы чиннар бирү өчен квалификация имтиханнарын кабул итү, муниципаль хезмәттә эш стажын билгеләү һәм аның тиешле еллар эшләгән чорын исәпләү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Аттестация комиссиясе кабул итә торган карарларга аттестация узу чорына йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген бетерү максатларында:

1.1. Арча район Советының оештыру-гомуми бүлеге башлыгы, Комиссия секретаре Г.Ә. Гапдерахманованың Комиссиядә әгъзалыгын вакытлыча туктатып торырга.

1.2. Комиссия составына комиссия секретаре итеп вакытлыча Р.Р.Гариповны - Арча муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесен кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев